ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм
Татарстан Республикасының аерым закон актларына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 7 өлешендәге $5^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 18 статьяның 19 өлешендәге 4 пунктында “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларыннан,” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 20 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары” сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 21 статьяның 1 өлешендә “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 22 статьяда:
а) 1 өлештә “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләрен “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләрен “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләренә алмаштырырга;

в) 3[1] өлештә “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләрен “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләрен “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) сайлаучылар исемлекләре, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалар (мөрәҗәгатьләр) реестры белән танышырга;”;

8 пунктта “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының” сүзләрен “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының” сүзләренә алмаштырырга;

6) 28 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләрне һәм вафат булу хакындагы актлар язмаларына төзәтүләр яисә үзгәрешләр кертү турындагы белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә “Граждан хәле актлары турында” 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан ала.”;

7) 29 статьяның 16 өлешендә:

бишенче җөмләдә “, шулай ук сайлаучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта” сүзләрен төшереп калдырырга, “гына” сүзен “генә” сүзенә алмаштырырга;

җиденче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Сайлаучылар исемлегендәге язма участок комиссиясе рәисенең имзасы белән, бу имзаны куйган датаны күрсәтеп, таныклана.”;

8) 66 статьяда:

а) 12 өлештә “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын,”, “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 14 өлеш өстәргә:

“14. Сайлау кампаниясе уздыру чорында сайлау комиссияләренә тиешле дәрәҗәдәге сайлаулар әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары “Россия

Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә агымдагы финанс елында сайлау комиссияләре тарафыннан бюджетның бердәм счетына күчерелергә тиеш түгел һәм алар тарафыннан тиешле сайлау кампаниясе тәмамланганчы шул ук максатларда файдаланылырга тиеш.”;

9) $73^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

10) 75 статьяның 16 өлешендә “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары булган йә” сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 76 статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларга бюллетеньнәр граждан паспортын яисә аны алмаштыручы документны күрсәтеп кенә бирелә.”;

б) 9 өлешнең дүртенче җөмләсен төшереп калдырырга;

12) $76^1$ статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

13) 77 статьяның 14 өлешендә “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләрен “Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы” сүзләренә алмаштырырга;

14) 78 статьяның $4^1$ өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

15) 79 статьяда:

а) 3 өлештә:

икенче җөмләне төшереп калдырырга;

өченче җөмләдә “һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 өлештә “, шулай ук участок сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары санын игълан итә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 9а юлына язып куя” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) $5^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$5^1$. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә, сайлаучыларның тавышларын санау алдыннан участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

1) тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын (нинди дә булса сәбәпләр аркасында киткән сайлаучылар санын исәпкә алмыйча);

2) сайлаучыларга тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге сайлаучылар имзалары саны буенча билгеләнә);

3) тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

4) вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (сайлаучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә; муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (округ комиссиясе) бинасында вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар санын, вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар исемлеге буенча тикшерелә).";

г) $6^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$6^1$. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә, әлеге статьяның $5^1$ өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң, шушы күрсәткечләрне керткән комиссия әгъзасы сайлаучылар исемлегенең һәр битенә имза сала, аннан соң бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санаганда шунда булган затларга хәбәр итә. Әлеге статьяның $5^1$ өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау күрсәткечләрен участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре игълан итә, сайлаучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, аларны үз имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр – тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына, ә тавышларны санауның техник чаралары кулланылган очракта, беркетмәнең зурайтылган рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына кертелә:

1) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган вакытка сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

2) 2а һәм 2б юлларына – вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

3) 3 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4) 4 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны.

Шуннан соң күзәтүчеләр һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар сайлаучылар исемлеге белән танышырга, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.";

д) 22 өлештә "(әлеге статьяның $6^1$ өлеше нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмадан тыш)" сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 23 өлештә "төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,", ", төргәкләнгән барлык бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны" сүзләрен төшереп калдырырга;

16) 80 статьяда:

а) 7 өлештә:

беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Түбәнгерәк сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләр буенча югарырак сайлау комиссиясе җыелма таблица һәм тавыш бирү йомгаклары турында (сайлаулар нәтиҗәләре хакында) беркетмә төзи.”;

икенче һәм өченче җөмләләрне төшереп калдырырга;

б) 13 өлештә “(законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган очракта 9а – 9е юлларына)” сүзләрен төшереп калдырырга;

17) 82 статьяда:

а) 1 өлештә “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын,” сүзләрен төшереп калдырырга;

18) 83 статьяның 3 өлешендә “Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе” сүзләрен “тиешле сайлау комиссиясе” сүзләренә алмаштырырга;

19) 91 статьяның $12^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

20) 93 статьяның $13^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

21) 95 статьяның 4 өлешендәге $2^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

22) $104^8$ статьяның $11^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

23) $104^9$ статьяның $13^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

24) $104^{11}$ статьяның 4 өлешендәге $2^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

25) 108 статьяның $16^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

26) 2 нче кушымтаның 7 пунктындагы беренче абзацын төшереп калдырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы референдумы турында” 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләрне һәм вафат булу хакындагы актлар язмаларына төзәтүләр яисә үзгәрешләр кертү турындагы белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы Федераль закон нигезендә “Граждан хәле актлары турында” 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан ала.”;

2) 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

“14. Референдум кампаниясе уздыру чорында референдум комиссияләренә референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары Федераль закон нигезендә агымдагы финанс елында референдум комиссияләре тарафыннан бюджетның бердәм счетына күчерелергә тиеш түгел һәм алар тарафыннан референдум кампаниясе тәмамланганчы шул ук максатларда файдаланылырга тиеш.”.

**3 статья**

“Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның “$е^1$” пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 21 статьяның “$д^1$” пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 24 статьяда;

а) 1 пунктта “бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“а) референдумда катнашучылар исемлекләре, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалар (мөрәҗәгатьләр) реестры белән танышырга;”;

4) 26 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләрне һәм вафат булу хакындагы актлар язмаларына төзәтүләр яисә үзгәрешләр кертү турындагы белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль

закон нигезендә “Граждан хәле актлары турында” 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан ала.”;

5) 27 статьяда:

а) 4 пунктта “йә гражданның бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булуы” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 15 пунктта:

бишенче җөмләдә “, шулай ук референдумда катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта” сүзләрен төшереп калдырырга, “гына” сүзен “генә” сүзенә алмаштырырга;

җиденче җөмләне түбәндәге бәян итәргә: “Референдумда катнашучылар исемлегендәге язма участок комиссиясе рәисенең имзасы белән, бу имзаны куйган датаны күрсәтеп, таныклана.”;

6) 45 статьяда:

а) 10 пунктта “бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

“12. Референдум кампаниясе уздыру чорында референдум комиссияләренә референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган жирле бюджет акчалары “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә агымдагы финанс елында референдум комиссияләре тарафыннан бюджетның бердәм счетына күчерелергә тиеш түгел һәм алар тарафыннан референдум кампаниясе тәмамланганчы шул ук максатларда файдаланылырга тиеш.”;

7) $49^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 51 статьяның 8 пунктында “Бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары булган референдумда катнашучылар күпләп көтелә торган референдум участогында, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 52 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларга бюллетеньнәр граждан паспортын яисә аны алмаштыручы документны күрсәтеп кенә бирелә.”;

б) 6 пунктта дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

10) $52^1$ статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

11) 54 статьяда:

а) $2^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктта “2 һәм $2^1$ пунктларында күрсәтелгән” сүзләрен “2 пунктында күрсәтелгән” сүзләренә алмаштырырга;

12) 55 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Референдумда катнашучыларның тавышларын санау алдыннан участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

а) тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санын (нинди дә булса сәбәпләр аркасында киткән референдумда катнашучылар санын исәпкә алмыйча);

б) референдумда катнашучыларга тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында бирелгән бюллетеньнәр санын (референдумда катнашучылар исемлегендәге референдумда катнашучылар имзалары саны буенча билгеләнә);

в) тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (референдумда катнашучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

г) вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (референдумда катнашучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә; муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар санын, вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар исемлеге буенча тикшерелә).”;

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң, шушы күрсәткечләрне керткән комиссия әгъзасы референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә имза сала, аннан соң бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санаганда шунда булган затларга хәбәр итә. Әлеге статьяның 5 пункты нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау күрсәткечләрен участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре игълан итә, референдумда катнашучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, аларны үз имзасы һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр – тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына, ә тавышларны санауның техник чаралары кулланылган очракта, беркетмәнең зурайтылган рәвешенең түбәндәге тиешле юлларына гына кертелә:

а) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

б) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

в) 5 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

г) 6 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны.

Шуннан соң күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар референдумда катнашучылар исемлеге белән танышырга, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы.”;

в) 20 пунктта “(әлеге статьяның 6 пункты нигезендә тикшерелә торган контроль чагыштырмадан тыш)” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 21 пунктта “төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,”, “, барлык төргәкләнгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының гомуми саны” сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 56 статьяда:

а) 6 пунктта бишенче абзацны төшереп калдырырга;

б) 12 пунктта “(әгәр законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш бирү каралган булса, 11а – 11е юлларына)” сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 58 статьяның 1 пунктында “, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 2 нче кушымтаның 5 пунктын төшереп калдырырга.

**4 статья**

“Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында” 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләрне һәм вафат булу хакындагы актлар язмаларына төзәтүләр яисә үзгәрешләр кертү турындагы белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә “Граждан хәле актлары турында” 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә Граждан хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан ала.”;

2) 39 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

“9. Чакыртып алу кампаниясе уздыру чорында чакыртып алу комиссияләренә чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә “Россия Саклык банкы” гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон нигезендә агымдагы финанс елында чакыртып алу комиссияләре тарафыннан бюджетның бердәм счетына күчерелергә тиеш түгел һәм алар тарафыннан чакыртып алу кампаниясе тәмамланганчы шул ук максатларда файдаланылырга тиеш.”.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казан, Кремль
2018 ел, 07 ноябрь
№ 83-ТРЗ